ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Гоголя, д.1, с.Акбаш, 423958

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Гоголь урамы, 1 йорт, Акбаш авылы, 423958

Тел./факс: (85593) 4-14-34, e-mail: Akbash.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 3** **« 31» января 2023 г.**

2023 елга Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлегендә җирләү хезмәтләренең
гарантияләнгән исемлеге нигезендә
күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен
раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 18.05.2007 ел, № 196 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге Советының 17.07.2019 №10 карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2023 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә, 7793,48 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлегендәге «2022 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 2022 елның 31 гыйнварындагы 7 номерлы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге карарының үз көчен югалтуын танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм

җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Акбаш авыл җирлеге

Башлыгы: Л.Р.Синагатуллина

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге
Башкарма комитетының
"31"январь 2023 ел. № 3
карарына

2023 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе

| Хезмәтләр исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3115,52 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 952,3 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3725,66 |
| Барлыгы | 7793,48 |

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге
Башкарма комитетының
"31"январь 2023 ел. № 3
карарына

2023 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе

| Хезмәт исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда ) |
|---|---|
| 1. Мәетне күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җәсәдне кәфенгә төрү | 723,02 |
| 3. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2392,5 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 952,3 |
| 5. Кабер казу һәм күмү) | 3725,66 |
| Барлыгы | 7793,48 |